**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Яңа Спас авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**31.01.2022 ел** **№47**

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Яңа Спас авыл җирлеге**
**Уставына үзгәрешләр**
**кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлегенең гамәлдәге Уставы нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынганнан соң бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар дәүләт теркәве узганнан һәм билгеләнгән тәртиптә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Н.В.Танчук**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районының
Яңа Спас авыл җирлеге
Советы карарына кушымта
« 31» январь 2021 ел № 47

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Яңа Спас авыл җирлеге**
**Уставына үзгәрешләр**

Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге Уставына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 5 статьяның 1 өлеше 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү торган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру таләпләрен раслау;»;
2. 39 статьяның 1 өлеше 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7) Россия Федерациясе гражданлыгы, яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, чит ил гражданлыгы (подданство) булу яисә яшәүгә рөхсәт төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданы документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;
3. 44 статьяның 1 өлеше 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9) Россия Федерациясе гражданлыгы, яисә аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу, чит ил гражданлыгы (подданство) булу яисә яшәүгә рөхсәт төре яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданы документы булу, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса;»;
4. 69 статьяның 8 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«-хокукый акт текстын Россия Юстиция министрлыгының "Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар" рәсми порталында (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф) урнаштыру.»;
5. 77 статьяның 7 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7. Чираттагы финанс елына һәм план чорына җирлек бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:
- Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели

торган Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләренә;
- Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча ачык хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документларга;
- җирлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләренә;
- җирлекнең социаль-икътисадый үсеше фаразына;
- озак сроклы чорга бюджет фаразына (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты);
- муниципаль программаларга (муниципаль программалар проектларына, күрсәтелгән программалар үзгәрешләре проектларына).»;
6. 86 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Җирлек уставы, Советның әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карары дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми рәвештә бастырылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм алар рәсми төстә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә. Җирлек башлыгы теркәлгән җирлек Уставын, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Совет карарын муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан "Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында" 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясы 6 өлешендә каралган муниципаль берәмлек уставын, муниципаль хокукый акт турында мәгълүматларны Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре уставларының дәүләт реестрына кертү турында хәбәрнамә кергәннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) тиеш.».